Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авыл Советы

# КАРАРЫ

04 сентябрь 2020 ел № 133

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл Советының 2020 елның 03 мартындагы «Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә турында»гы 121 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 07 июлендәге 564 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифасында тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләкләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифасында тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләкләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 20 июлендәге 09/13-09/3471 номерлы хатын карап

Борискино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл Советының 2020 елның 03 мартындагы 121 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитеты (алга таба - җирлек башкарма комитеты) тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү көненә кадәр 30 календарь көне кала бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - Финанс-бюджет палатасы) түбәндәге документларны тапшыра:

- муниципаль хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы күләме турында белешмә;

- муниципаль хезмәттәге эш стажы турында, җитәкче һәм кадрлар хезмәте тарафыннан расланган белешмә;

- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт китабы күчермәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;

- кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хәрби билет күчермәсен (элеге документ муниципаль хезмәткәрдә булганда);

- сыйныф чинын бирү, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладка кирә торган акчалата өстәмәләр билгеләү турындагы карардан өземтәләр;

- җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан таныкланган форма (кушымта) буенча башкарылган бер тапкыр бүләкләүнең исәп-хисабы;

- муниципаль хезмәткәрнең эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.».

2 Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Борискино авылы, Үзәк урам, 61 йорт; Березовка бистәсе, Үзәк урам, 16 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Борискино авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Борискино авыл
җирлеге Башлыгы Ж.С.Илалов